ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм $17^1$ статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 157-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

---

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм $17^1$ статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 157-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2026 елның 19 феврале
№ 552-VII ДС

157-7 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм $17^1$ статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2025, № 85 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 17 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне яллаучы вәкиленә түбәндәгеләр тапшыра:

2) дәүләт хезмәткәре.»;

б) 2 өлештә «дәүләт хезмәткәренең һәм аның гаиләсе әгъзаларының» сүзләрен «дәүләт хезмәткәре тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга, « турындагы белешмәләрне дәүләт хезмәткәре тарафыннан» сүзләрен «турында әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләрне» сүзләренә алмаштырырга»;

в) 4 өлештә « Дәүләт хезмәткәренең һәм аның гаиләсе әгъзаларының түләү мөмкинлеген урнаштыру яисә билгеләү өчен» сүзләрен «Дәүләт хезмәткәренең һәм аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының түләү мөмкинлеген урнаштыру яисә билгеләү өчен» сүзләренә алмаштырырга, «дәүләт

хезмәткәренең һәм аның гаиләсе әгъзаларының керемнәре» сүзләрен «әлеге статья нигезендә тапшырыла торган керемнәре» сүзләренә алмаштырырга;

г) 5 өлештә «Дәүләт хезмәткәренең һәм аның гаиләсе әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы» сүзләрен «Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында әлеге статья нигезендә тапшырыла торган» сүзләренә алмаштырырга;

д) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

е) 6[1] өлештә «үзенең керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук үз гаиләсе әгъзаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр» сүзләрен «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 7 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

2) 17[1] статьяда:

а) 1 өлештә «биләүче дәүләт хезмәткәре» сүзләреннән соң «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнар турындагы белешмәләрне» сүзләрен өстәргә; «үз чыгымнары, шулай ук үз гаиләсе әгъзаларының чыгымнары турындагы белешмәләрне» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәткәренең һәм аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе Президенты норматив хокукый актларында һәм башка Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

в) 4 өлештә «үз чыгымнары, шулай ук үз гаиләсе әгъзаларының чыгымнары турында белешмәләрне» сүзләрен «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда каралган чыгымнар турындагы белешмәләрне» сүзләренә алмаштырырга».

**2 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 47 (I өлеш), № 79 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2025, № 75 (I өлеш); 2026, № 1 (; I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 18 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә дәгъва итүче граждан, муниципаль хезмәткәр «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда яллаучы вәкиленә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында әлеге законда каралган белешмәләр тапшыра. Күрсәтелгән белешмәләр Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган белешмәләр бирү өчен билгеләнгән тәртиптә, вакытта һәм рәвештә тапшырыла.»;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль вазыйфаны биләүче муниципаль хезмәткәр чыгымнар турында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль закон) каралган белешмәләрне Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан шундый белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм рәвештә тапшырырга тиеш.»;

в) 3 өлештә «2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 4 өлештә «керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 5 өлештә «Муниципаль хезмәткәрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрдән» сүзләрен «Муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләрдән» сүзләренә алмаштырырга;

е) 6 өлештә «Муниципаль хезмәткәрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы белешмәләрдән» сүзләрен

«Муниципаль хезмәткәр тарафыннан әлеге статья нигезендә тапшырыла торган белешмәләрдән» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 7 өлештә «үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрне» сүзләрен «керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган белешмәләрне һәм чыгымнары турында «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» Федераль законда каралган белешмәләрне» сүзләренә алмаштырырга;

з) 11 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләрне, күрсәтелгән вазыйфаны биләүче зат әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән белешмәләрне Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Рәисенә тапшыра.»;

и) 12 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

к) 14 өлештә «2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 19 статьяның 3 өлешендәге 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законда каралган белешмәләрне».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 17[1] статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 17[1] статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль законны (алга таба – 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон) үтәү максатыннан эшләнде.

2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль закон белән дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе үзгәртелде.

Закон проекты нигезендә дәүләт хезмәте (муниципаль хезмәт) Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында билгеләнгән исемлекләргә кертелгән дәүләт хезмәте (муниципаль хезмәт) вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләре (муниципаль хезмәткәрләр), контракт буенча җирле администрация башлыклары тарафыннан әлеге белешмәләр элеккечә ел саен түгел, ә җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча белешмәләр тапшыру елыннан алдагы (хисап чорында) календарь ел дәвамында алыш-биреш башкарылган очракта, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы тиешле вазыйфаны биләүче затның, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларның соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, тапшырылачак.

Закон проекты нигезендә керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне түбәндәгеләрне тапшырырга тиеш:

- дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар;
- Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән исемлекләргә кертелгән дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы дәүләт хезмәткәрләре;
- Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтендә федераль кадрлар резервына керүне дәгъвалаучы дәүләт хезмәткәрләре һәм гражданнар;
- вазыйфаларга башка дәүләт органыннан күчерү тәртибендә билгеләнүче дәүләт хезмәткәрләре.

Шулай ук күрсәтелгән белешмәләрне түбәндәгеләр тапшырырга тиеш:

- Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән исемлекләргә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы муниципаль хезмәткәрләр;

- Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән исемлекләргә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар.

Моннан тыш, закон проекты белән Интернет челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бастырып чыгару зарурлыгы юкка чыгарыла.

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 17$^{1}$ статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары**

## ИСЕМЛЕГЕ

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 17$^{1}$ статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнары актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм 17$^{1}$ статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы Указына һәм «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнар һәм дәүләт граждан хезмәткәрләре тапшыра торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең эш урынында үз-үзен тоту таләпләрен үтәүне тикшерү турында» Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 1 ноябрендәге ПУ-711 номерлы Указына үзгәрешләр кертү таләп ителә.

**«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм $17^1$ статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17 һәм $17^1$ статьяларына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.